ПРОЕКТ

**Төп гомуми белем бирү программалары буенча**
**төп дәүләт имтиханы (ТДИ) формасында**
**гомуми дәүләт йомгаклау аттестациясе**

# 2022 нче елда
# ҖӘМГЫЯТЬ БЕЛЕМЕННӘН төп дәүләт имтиханын үткәрү өчен контроль үлчәү материалларының күрсәтмә варианты

«ПЕДАГОГИК ҮЛЧӘНЕШЛӘР ФЕДЕРАЛЬ ИНСТИТУТЫ»
Федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесе тарафыннан әзерләнде

# ҖӘМГЫЯТЬ БЕЛЕМЕ буенча төп дәүләт имтиханы

## 2022 нче ел өчен төп дәүләт имтиханының контроль үлчәү материалларының демонстрацион вариантына аңлатмалар

2022 нче елгы күрсәтмә вариант белән танышканда, күрсәтмә вариантка кертелгән биремнәрнең, 2022 нче елда КҮМ вариантлары ярдәмендә тикшереләчәк барлык эчтәлек элементларын да чагылдырмавын уны истә тотарга кирәк. 2022 нче елда җәмгыять белеме буенча имтиханда тикшерелергә ихтимал контрольдә тотылырга мөмкин булган эчтәлек элементларының тулы исемлеге, www.fipi.ru сайтында – урнаштырылган төп дәүләт имтиханын үткәрү өчен укучыларны имтиханга әзерләү дәрәҗәсенә карата таләпләр кодификаторында китерелгән.

Күрсәтмә вариантта имтихан эшенең һәр позициясендә биремнең мөмкин булган барлык формулировкаларын үз эченә алган биремнәрнең конкрет мисаллары тәкъдим ителгән.
Имтихан вариантларын төзү өчен кулланыла торган барлык биремнәр дә fipi.ru сайтында ТДИ биремнәренең ачык банкында урнаштырылган.

Күрсәтмә вариант имтиханда катнашучыга һәм киң җәмәгатьчелеккә булачак имтихан эшенең структурасын, биремнәрнең санын һәм формасын, шулай ук катлаулылык дәрәҗәсен турында күзаллау булдыру өчен тәкъдим ителә. Имтихан эшенең күрсәтмә вариантында бирелгән киңәйтелгән җавапны таләп итә торган биремнәрнең үтәлешен бәяләү критерийлары киңәйтелгән җавапларның тулылыгына һәм дөреслегенә куелган таләпләрне күзалларга мөмкинлек бирәчәк.

Бу мәгълүматлар имтиханда катнашачак укучыларга 2022 нче елда җәмгыять белеме буенча имтиханга тапшыруга әзерләнү стратегиясен булдырырга мөмкинлеге бирәләр.

Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәте 2022 ©

# 2022 нче елда ҖӘМГЫЯТЬ БЕЛЕМЕННӘН төп дәүләт имтиханын үткәрү өчен контроль үлчәү материалларының күрсәтмә варианты

## Эшне башкару буенча инструкция

Имтихан эше 24 биремнән тора: кыска җаваплар таләп иткән 16 бирем һәм киңәйтелгән җаваплар таләп иткән 8 бирем.

Җәмгыять белеме буенча имтихан эшен башкаруга 3 сәгать (180 минут) вакыт бирелә.

2-4, 7-11, 13, 14, 16-18 биремнәренә җаваплар дөрес җавапка туры килгән бер цифр рәвешендә язып куела. 15, 19 нчы биремнәрнең җаваплары цифрларның эзлеклелеге булып тора. 20 нче биремнең җавабы сүз (сүзтезмә) була. Җавапларны башта өтерләр, башка өстәмә символлар куймыйча, ара калдырмыйча, имтихан эше биремнәре язылган битләргә языгыз, аннан соң 1 нче номерлы бланкка күчерегез.

1, 5, 6, 12, 21-24 нче биремнәр 2 нче номерлы җавап бланкына язылалар. 21-24 биремнәрне башкару өчен тексттан кирәкле мәгълүматны сайлап алырга, аның аерым нигезләмәләрен ачарга (шул исәптән мисалларда); тексттагы мәгълүматларны курсны өйрәнү барышында алган белемнәр белән чагыштырырга; булган белемнәрне социаль ситуацияләрне анализлау өчен файдаланырга; үз фикереңне әйтергә һәм нигезләргә кирәк.

Барлык бланклар ачык кара төстәге күренгән кара белән тутырыла. Гельле яки капилляр ручкалар куллану рөхсәт ителә.

Биремнәрне үтәгәндә караламалардан файдалана аласыз. **Эшне бәяләгәндә, караламалардагы, шулай ук контроль бәяләү материаллары текстындагы язмалар исәпкә алынмый.**

Үтәлгән биремнәр өчен алынган баллар кушыла. Мөмкин кадәр күбрәк биремнәр үтәргә һәм күбрәк балл җыярга тырышыгыз.

Эшегезне тәмамлаганнан соң, 1 нче һәм 2 нче номерлы бланк җавапларының тиешле номер астында язылуын тикшереп чыгыгыз.

***Уңышлар телибез!***

Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәте 2022 ©

***1, 5, 6 һәм 12 нче биремнәрнең җаваплары өчен 2 нче номерлы җавап бланкын кулланыгыз. Башта биремнең номерын, аннан соң аның җавабын язып куегыз. Җавапларны төгәл һәм аңлашылырлык итеп языгыз.***
***2-4, 7-11, 13-20 биремнәренә җаваплар булып цифр, цифрлар эзлеклелеге яки сүз (сүзтезмә) тора. Башта җавапларны эшнең текстында күрсәтегез, аннан соң аларны 1 НЧЕ НОМЕРЛЫ ҖАВАПЛАР БЛАНКЫНА, тиешле бирем номерыннан уң якка беренче шакмактан башлап өтерләр, башка өстәмә символлар куймыйча, ара калдырмыйча күчереп языгыз. Һәрбер цифрны яки хәрефне аерым шакмакка бланкта китерелгән үрнәкләр нигезендә языгыз.***

**1** Түбәндәге төшенчәләрнең кайсы икесе, беренче чиратта, җәмгыятьнең сәяси өлкәсен сурәтләгәндә кулланыла?

*Страта; керем; хөкүмәт, демократия, милек.*

Туры килә торган төшенчәне язып алыгыз һәм берсенең мәгънәсен ачыгыз. Җавапны биремнең тәртип номерын күрсәтеп, 2 нче номерлы җаваплар бланкына язып куегыз.

**2** Дәрестә укучылар Россия Федерациясенең гаилә законнарын бер гаилә парының аерылышу турындагы эш мисалында өйрәнделәр. Түбәндәгеләрнең кайсысы (кайсылары) әлеге уку эшчәнлеге субъекты булып тора?
1) гаилә законнары
2) дәрес
3) мәктәп укучылары
4) гаилә пары

Җавап: ☐

**3**

Гимназиянең унынчы сыйныф укучысы Виолетта балаларның абруйлы саналган актерлык осталыгы конкурсында җиңде. Ул шулай ук балалар вокал студиясендә дә шөгыльләнә. Виолетта белем алуның кайсы дәрәҗәсендә?

1) башлангыч гомуми белем бирү
2) төп белем бирү
3) урта белем бирү
4) урта һөнәри белем бирү

Җавап: ☐

**4**

Хәзерге дөньяда фәннең роле турындагы түбәндәге бу фикерләр дөресме?

А. Фән кешегә әйләнә-тирә дөнья турындагы белемнәрен системалаштырырга булыша.

Б. Фән нәтиҗәләрнең дөреслегенә омтыла.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

Җавап: ☐

**5**

Фотографияне карагыз.



Гаилә әгъзалары икътисади эшчәнлекнең нинди төрен башкара? Җәмгыять белемен, социаль тормыш фактларын һәм шәхси социаль тәҗрибәне кулланып, әлеге эшчәнлекне рациональ рәвештә гамәлгә ашыруның ике кагыйдәсен формалаштырыгыз һәм һәр кагыйдәне кыскача гына аңлатыгыз. Җавапны, биремнең номерын күрсәтеп, 2 нче номерлы җаваплар бланкында языгыз.

**6**

Балигъ яшьтәге булган Роман Р.-га билгесез абоненттан SMS-хәбәр килде: “Хөрмәтле клиент! Картагыздан санкцияләнмәгән рәвештә акча алырга омтылыш булганлыктан, картадан куллану туктатылган (заблокирована). Счеттан файдалануны тергезү өчен * * * * телефоны аша картагыз буенча мәгълүмат хәбәр итегез: № һәм PIN-код. Якын арада бу мәсьәлә хәл ителәчәк. Банк Д.".
Әлеге хәлнең Роман Р. -ның шәхси финанслары өчен куркынычы нидә? Бу ситуациядә аңа ничек дөрес гамәл кылырга? Аңа бу ситуациядә ничек дөрес эшләргә?
Җавапны биремнең номерын күрсәтеп, 2 нче номерлы җаваплар бланкында языгыз.

**7**

Түбәндә санап үтелгәннәрнең кайсысы җитештерү факторларына (ресурсларына) карый?
1) хезмәт
2) керем
3) салымнар
4) хезмәт хакы

Җавап: ☐

**8**

Z илендә товар җитештерү һәм акча әйләнеше бар. Нинди өстәмә мәгълүмат, Z иленең икътисады базар характерына туры килүеә турында нинди дип нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирәчәк?
1) Дәүләт хезмәткәрләрнеңгә эш хакы күләмен билгели.
2) Финанс министрлыгы алынган табышны ничек кулланырга дигән мәсьәләне хәл итә.
3) Балигъ булмаган хезмәткәрләргә хезмәт шартларына карата ташламалар бирелә.
4) Җитештерүче нәрсәне һәм күпме җитештерергә кирәклекне мөстәкыйль билгели.

Җавап: ☐

**9**

Ресурсларның чикләнгән булуы турындагы фикерләр дөресме?

А. Ресурсларның чикләнгән булу проблемасы хәзерге фән белән тулысынча хәл ителергә мөмкин.

Б. Ресурсларның чикләнгәнлеге булуы җәмгыятьнең ихтыяҗларының үсүенә белән бәйле.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

Җавап: ☐

**10**

Нинди социаль рольне яшүсмерләр дә, олылар да башкара алалар?
1) кулланучы
2) сайлаучы
3) урта мәктәп укучысы
4) машина йөртүче

Җавап: ☐

**11**

Социаль конфликт  турындагы фикерләр дөресме?

А. Социаль конфликт һәрвакытта да тискәре нәтиҗәләргә китерә.


Б. Социаль конфликтлар үсеш формасы һәм характеры буенча аерылалар.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

Җавап: ☐

**12** Социологик сораштырулар барышында, Z иленең балигъ булган халкына, кеше өчен аларга хокукның кайсы тармакларын күбрәк белү мөһимрәк булуын (белгечлек буенча юристка түгел) билгеләргә тәкъдим ителдете. (Берничә җавап бирергә мөмкин иде.)

Сораштыру нәтиҗәләре (җавап бирүчеләр санының % ында) гистограммада күрсәтелгән:




а) охшашлык; б) сораштыруда катнашучыларның позицияләрендәге аерма турында берәр нәтиҗә формалаштырыгыз. Сез күрсәткән а) охшашлыкның; б) аерманың нәрсә белән аңлатылуы турында фаразларыгызны белдерегез. Җавапны, биремнең номерын күрсәтеп, 2 нче номерлы җаваплар бланкына языгыз.

**13** Z илендә хакимият бер сәяси партиягә карый. Бу партия гражданнарның хокукларын чикли һәм аларның шәхси тормышын тулысынча контрольдә тотарга омтыла. Сайлаулар даими рәвештә үткәрелүгә карамастан, Парламент ул әлеге партия әгъзаларыннан гына формалаша. Илдә бер сәяси идеология өстенлек итә. Алынган мәгълүматлар нигезендә Z дәүләтен нинди төр дәүләт дип, бәяләргә дигән нәтиҗә ясарга мөмкин?

1) демократик
2) монархик
3) федератив
4) тоталитар

Җавап: 

**14** Референдум турындагы фикерләр дөресме?

А. Референдум, бөтен җәмгыять һәм һәр граждан өчен мөһим булган мәсьәләләр буенча, бөтен халыкның тавыш бирүен күздә тота.

Б. Референдумда кабул ителгән карарлар югары юридик көчкә ия һәм дәүләт хакимияте органнары тарафыннан раслануга мохтаҗ түгел.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

Җавап: ☐

**15** Кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре белән хокуклар төркемнәре арасындагы тәңгәллекне билгеләгез: беренче баганаың һәр элементына икенче баганадан тиешле элементны сайлап алыгыз.

| КЕШЕ ҺӘМ ГРАЖДАН ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ ИРЕКЛӘРЕ | ХОКУК ТӨРКЕМНӘРЕ |
|---|---|
| А) тормышка хокук | 1) гражданлык (шәхси) |
| Б) дәүләт эшләре белән идарә итүдә катнашу хокукы | 2) сәяси |
| В) эшкуарлык эшчәнлеге иреге | 3) социаль-икътисади |
| Г) вөҗдан һәм дин тоту иреге | |
| Д) сайлау һәм сайлану хокукы | |

Сайлап алынган цифрларны таблицага тиешле хәрефләр астына язып куегыз.

Җавап:

| А | Б | В | Г | Д |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

**16** Хокукый нормалар, башка социаль нормалардан аермалы буларак,
1) дәүләт көче белән хуплана
2) кешеләрнең үз-үзләрен тотышын җайга сала
3) җәмәгать фикере көченә таяна
4) үз-үзеңне тоту үрнәкләрен үз эченә ала

Җавап: ☐

Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәте 2022 ©

**17** Гражданин К. улына туган көненә үз автомобилен бүләк иткән. Бу мисал, барыннан да элек, гражданин К.-ның үз милкенә карата милекче буларак нинди хокукын күрсәтә?

1) биләү
2) мирас
3) куллану
4) үзе теләгәнчә эш итү

Җавап: ☐

**18** Россия Федерациясендә коррупциягә каршы көрәш турындагы фикерләр дөресме?

Россия Федерациясендә коррупциягә каршы тору түбәндәге принципка нигезләнеп гамәлгә ашырыла:
А. кешенең һәм гражданның төп хокукларын һәм ирекләрен тану, тәэмин итү һәм яклау.
Б. дәүләтнең гражданлык җәмгыяте институтлары, халыкара оешмалар һәм физик затлар белән хезмәттәшлек итә.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

Җавап: ☐

**19** Укытучы, кешенең асылын ачып, кешенең һәм башка җан ияләренең охшаш сыйфатларын, шулай ук кешене башка тереклек ияләреннән аера торган сыйфатларын характерлады.
Таблицаның беренче баганасына охшаш якларның тәртип номерларын, ә икенче баганага аермалы якларның тәртип номерларын сайлагыз һәм язып куегыз.

1) әйләнә-тирә мохит шартларына җайлашу
2) эшчәнлекнең максатларын һәм бурычларын күрсәтүгә сәләт
3) инстинктлар һәм рефлекслар
4) аң һәм сөйләм

Җавап:

| Охшаш яклар | | Аермалы яклар | |
|---|---|---|---|
| | | | |

**20** Таблицадагы бушлыкларны тутырыгыз.

| Дәүләт хөкүмәте субъекты | Вәкаләтләр |
|---|---|
| Россия Федерациясенең ... | Федераль бюджетны эшли һәм Дәүләт Думасына тәкъдим итә, үтәлешен тәэмин итә |
| Дәүләт Думасы | Россия Федерациясе законнарын кабул итә |

Җавап: ___________________________ .

***Текстны укыгыз һәм 21-24 нче биремнәрне үтәгез. Биремнәргә җавапларны язу өчен 2 нче номерлы җаваплар бланкыннан файдаланыгыз. Башта биремнең номерын, аннары аңа тулы җавапны языгыз. Җавапларны ачык һәм аңлаешлы итеп язып куегыз.***

Без белем, һөнәри күнекмәләр кеше язмышында хәлиткеч роль уйнаячак гасырга керәбез. Гел катлауланып тора торган белемнән башка эшләргә, файда китерергә мөмкин булмаячак.... Кеше яңа идеяләр кертәчәк, машина уйлый алмый торган нәрсәләр турында уйлаячак. Ә моның өчен кешенең гомуми интеллигенциясе, аның яңа әйберләр уйлый алу һәм, әлбәттә, әхлакый җаваплылык булдыру кебек, машина берничек тә үти алмый торган сәләт кирәк булачак. Кешегә авыр һәм катлаулы бурыч – кеше генә түгел, ә фән кешесе, машиналар һәм роботлар гасырындагы барлык эшләр өчен әхлакый җавап бирүче кеше булу бурычы йөкләнә. Гомуми белем киләчәк кешесен, иҗат кешесен, барлык яңалыкны уйлап табучы һәм һәрбер уйланып табылганнарга әхлакый җавап бирә торган кешене булдыра ала.

Уку, белем алу – менә нәрсә кирәк кешегә яшь чактан ук. Укырга, белем алырга һәрвакыт кирәк. Барлык күренекле галимнәр гомерләренең соңгы көненә хәтле укытып кына калмаганнар, ә үзләре дә укыганнар. Белем алудан туктасаң – укыта да алмыйсың. Чөнки белем үсә һәм катлаулана. Шуны да истә тотарга кирәк, белем алу өчен иң уңайлы вакыт – яшьлек. Нәкъ менә яшь чакта, балачакта, яшьлектә кешенең аңы күп әйберләрне кабул итәргә сәләтле.

Вакытыгызны буш нәрсәләргә, авыр эшләргә караганда да ардырта торган «ял итү»ләргә әрәм итмәгез, үзегезнең аек акылыгызны мәгънәсез «мәгълүматлар» агымы белән тутырмагыз. Үзегезне яшь чакта гына бик җиңел һәм тиз үзләштереп була торган белем һәм күнекмәләр алу өчен саклагыз.

Менә шунда мин яшь кешенең авыр итеп көрсенеп куюын ишетәм: нинди күңелсез тормыш тәкъдим итәсез сез безнең яшьләргә? Укырга гына. Ә ял, күңел ачу кайда соң? Безгә шатланырга, куанырга да ярамый мени инде?

Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәте 2022 ©

Юк. Күнекмәләр һәм белем алу – шул ук спорт. Без анда шатлык таба алмаганда белем алу да бик авыр була. Белем алуны яратырга кирәк һәм ял һәм күңел ачу төрләренең акыллы, нәрсәгә дә булса өйрәтергә, тормышта кирәк булган ниндидер сәләтләрне үстерергә ярдәм итә торганнарын сайлый белергә кирәк…

Укырга өйрәнергә өйрәнегез!

*(Д.С.Лихачёв)*

**21** Текстның планын төзегез. Моның өчен текстның төп мәгънәви фрагментларын аерып чыгарыгыз һәм аларга исем кушыгыз.

**22** Автор XXI гасырда җитештерүдә кеше ролен ничек тасвирлый? Аның фикеренчә, кешегә нинди сыйфатлар кирәк булачак? (Теләсә нинди ике сыйфатны күрсәтегез.) Ни өчен, автор фикеренчә, яшь кешегә кечкенәдән үк укырга кирәк? (Текстны файдаланып, ике сәбәпне күрсәтегез.)

**23** Автор яшьләргә нинди ял һәм күңел ачу төрләре тәкъдим итә? Мондый төрләргә ике мисал китерегез; һәр очракта бу төрнең нинди сыйфат үстерүен күрсәтегез.

**24** Автор «һәрвакыт укырга кирәк» дип саный. Тексттан һәм җәмгыять белеменнән белгәннәрегезне файдаланып, өзлексез белем алуның кеше гомеренең буеннан-буена кирәклеген ике аргумент (аңлатма) белән раслагыз.

***Барлык җавапларны да эшләрне башкару буенча инструкция нигезендә***
***1 һәм 2 нче санлы җаваплар бланкларына күчерергә онытмагыз.***
***Һәр җавапның тиешле бирем номеры янында язылуын тикшерегез!***

Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәте 2022 ©

## Җәмгыять белеме буенча имтихан эшен бәяләү системасы

15 нче биремнән тыш, кыска җаваплы һәр биремнең дөрес җавабы өчен 1 балл куела. 15 нче бирем түбәндәге принцип буенча бәяләнә: 2 балл – хаталар юк; 1 балл – бер хата җибәрелгән; 0 балл – ике һәм аннан да күбрәк хата җибәрелгән.

| Бирем номеры | Дөрес җавап | Бирем номеры | Дөрес җавап |
|---|---|---|---|
| **2** | 3 | **13** | 4 |
| **3** | 3 | **14** | 3 |
| **4** | 3 | **15** | 12312 |
| **7** | 1 | **16** | 1 |
| **8** | 4 | **17** | 4 |
| **9** | 2 | **18** | 3 |
| **10** | 1 | **19** | 1324 <яки> 3142 <яки> 1342 <яки> 3124 |
| **11** | 2 | **20** | Хөкүмәт |

Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәте 2022 ©

## Җәенкеләндерелгән җаваплы биремнәр үтәлешен бәяләү критерийлары

**1** Түбәндәге төшенчәләрнең кайсы икесе, беренче чиратта, җәмгыятьнең сәяси өлкәсен сурәтләгәндә кулланыла?

*Страта; керем; хөкүмәт, демократия, милек.*

Туры килә торган төшенчәне язып алыгыз һәм берсенең мәгънәсен ачыгыз.

Җавапны биремнең тәртип номерын күрсәтеп, 2 нче номерлы җаваплар бланкына язып куегыз.

| **Дөрес җавап эчтәлеге һәм бәяләү буенча күрсәтмәләр** (җавапның мәгънәсен бозмый торган башка формулировкалары рөхсәт ителә) | **Баллар** |
|---|---|
| Дөрес җавапта түбәндәге элементлар булырга тиеш:<br>1) хакимият, демократия төшенчәләре;<br>2) төшенчәнең мәгънәсе, мәсәлән: хакимият – үз ихтыярыңны тагу, идарә итү яки башка кешеләргә йогынты ясау мөмкинлеге / демократия – хакимият чыганагы халык үзе булган сәяси режим.<br>(Башка, мәгънәсе буенча якын билгеләмә яки төшенчәнең мәгънәсен аңлату китерелергә мөмкин.) | |
| Ике дөрес төшенчә күчерелеп язылган, теләсә кайсы берсенең мәгънәсе ачылган | 2 |
| Дөрес төшенчәләр белән беррәттән. бер яки берничә артык төшенчә язылган, дөрес төшенчәнең мәгънәсе ачылган.<br>ЯКИ Ике дөрес төшенчә генә күчерелеп язылган.<br>ЯКИ Бер дөрес төшенчә генә күчерелеп язылган, аның мәгънәсе ачылган. | 1 |
| Дөрес төшенчәләр белән беррәттән, бер яки берничә артык төшенчә язылган, артык төшенчәнең генә мәгънәсе ачылган.<br>ЯКИ Дөрес төшенчәләр белән беррәттән, бер яки берничә артык төшенчә язылган, дөрес төшенчәнең мәгънәсе ачылмаган яки дөрес ачылмаган.<br>ЯКИ Бер генә дөрес төшенчә язылган.<br>ЯКИ Биремнең таләпләренә туры килми торган гомуми характердагы фикер йөртүләр генә китерелгән.<br>ЯКИ Җавап дөрес түгел | 0 |
| *Максималь балл* | *2* |

**5** Фотографиядә гаилә сурәтләнгән.



Гаилә әгъзалары икътисади эшчәнлекнең нинди төрен башкара? Җәмгыять белемен, социаль тормыш фактларын һәм шәхси социаль тәҗрибәне кулланып, әлеге эшчәнлекне рациональ рәвештә гамәлгә ашыруның ике кагыйдәсен формалаштырыгыз һәм һәр кагыйдәне кыскача гына аңлатыгыз. Җавапны биремнең номерын күрсәтеп, 2 нче номерлы җаваплар бланкында языгыз.

| **Дөрес җавап эчтәлеге һәм бәяләү буенча күрсәтмәләр**<br>(җавапның мәгънәсен бозмый торган башка формулировкалары рөхсәт ителә) | **Баллар** |
|---|---|
| Дөрес җавапта түбәндәге элементлар булырга тиеш:<br>1) сорауга җавап: туклану продуктлары сатып алу / хуҗалык - көнкүреш / кулланучы эшчәнлеге һ. б.;<br>(Фоторәсемнәрдәге сурәтләрнең асылын бозмый торган башка җавап та китерелергә мөмкин.)<br>2) аңлатмалар белән ике кагыйдә, әйтик:<br>– алдан ук сатып алырга теләгән бөтен нәрсәне планлаштырырга һәм язарга, исемлек төзергә (югыйсә, артык әйберне сатып алу ихтималы артачак. Моннан тыш, ыгы-зыгыда кирәкле әйберне сатып алырга онытырга мөмкин);<br>- товарны күз карашы биеклегендә түгел, ә югарырак яки түбәнрәк киштәләрдән алырга (еш кына сатып алучының күз карашы биеклегендә урнаштырылган барлык товарлар түбән яки югары киштәләрдә яткан шундый ук товарларга караганда кыйммәтрәк була. Иң элек барлык киштәләрдәге кирәкле продуктларны игътибар белән карарга һәм бәяләрен чагыштырырга кирәк.)<br>(Башка кагыйдәләр формалаштырылырга, башка аңлатмалар китерелергә мөмкин.) | |

| | |
|---|---|
| Сорауга дөрес җавап бирелгән, ике кагыйдә (барлыгы биш элемент) формалаштырылган һәм аңлатылган. | 3 |
| Сорауга дөрес җавап бирелгән, бары тик ике-өч башка элемент кына китерелгән | 2 |
| Сорауга дөрес җавап бирелгән, бары тик бер генә башка элемент китерелгән | 1 |
| Сорауга дөрес җавап кына бирелгән.<br>ЯКИ Башка элементларның булуына бәйсез рәвештә сорауга дөрес җавап бирелмәгән (сорауга җавап юк).<br>ЯКИ Биремнең таләпләренә туры килми торган гомуми характердагы фикер йөртүләр генә китерелгән.<br>ЯКИ Җавап дөрес түгел | 0 |
| *Максималь балл* | *3* |

**6**


Балигъ булган Роман Р.-га билгесез абоненттан SMS-хәбәр килде: "Хөрмәтле клиент! Картагыздан санкцияләнмәгән рәвештә акча алырга омтылыш булганлыктан, картадан куллану туктатылган (заблокирована). Счеттан файдалануны тергезү өчен * * * * телефоны аша картагыз буенча мәгълүмат хәбәр итегез: № һәм PIN-код. Якын арада бу мәсьәлә хәл ителәчәк. Банк Д.". Әлеге хәлнең Роман Р. -ның шәхси финанслары өчен куркынычы нидә? Аңа бу ситуациядә ничек дөрес эшләргә?

| **Дөрес җавап эчтәлеге һәм бәяләү буенча күрсәтмәләр**<br>(җавапның мәгънәсен бозмый торган башка формулировкалары рөхсәт ителә) | **Баллар** |
|---|---|
| Дөрес җавапта түбәндәге элементлар булырга тиеш:<br>1) беренче сорауга җавап, мәсәлән: мөгаен, болар конфиденциаль мәгълүматны алырга һәм счеттан барлык акчаларны кулга төшерергә планлаштырган алдакчылардыр;<br>2) икенче сорауга җавап, мәсәлән: бер генә очракта да банк счеты һәм карта номерын, PIN-кодны хәбәр итмәскә; клиентлар өчен “Кайнар линия”гә һәм/яки банк куркынычсызлык хезмәтенә мөрәҗәгать итәргә кирәк.<br>Сорауларга җаваплар башка, мәгънәсе буенча якын формулировкаларда китерелергә мөмкин. | |
| Ике сорауга дөрес җавап бирелгән | 2 |
| Теләсә кайсы бер сорауга гына дөрес җавап бирелгән | 1 |
| Биремнең таләпләренә туры килми торган гомуми характердагы фикер йөртүләр генә китерелгән.<br>ЯКИ Җавап дөрес түгел | 0 |
| *Максималь балл* | *2* |

Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәте 2022 ©

**12** Z иленең балигъ булган халкына социологик сораштырулар барышында аларга хокукның кайсы тармакларын күбрәк белү кеше өчен мөһимрәк булуын (белгечлек буенча юристка түгел) билгеләргә тәкъдим итте. (Берничә җавап бирергә мөмкин иде.)

Сораштыру нәтиҗәләре (җавап бирүчеләр санының %ында) гистограммада күрсәтелгән.




а) Охшашлык; б) сораштырылучыларның позицияләрендәге аерма турында берәр нәтиҗә формалаштырыгыз. Сез күрсәткән а) охшашлыкның; б) аерманың нәрсә белән аңлатылуы турында фаразларыгызны белдерегез. Җавапны, биремнең номерын күрсәтеп, 2 нче номерлы җаваплар бланкына языгыз.

| **Дөрес җавап эчтәлеге һәм бәяләү буенча күрсәтмәләр**<br>(җавапның мәгънәсен бозмый торган башка формулировкалары рөхсәт ителә) | **Баллар** |
|---|---|
| Дөрес җавапта нәтиҗәләр ясалырга һәм фаразлар әйтелергә тиеш:<br>а) охшашлык турында, мәсәлән: ике төркемгә караган гражданнар да бертигез дәрәҗәдә, кешегә конституциядә язылган хокукларны белергә кирәк дип саный (чөнки һәр граждан үзенең хокукларын һәм бурычларын, конституцион төзелеш нигезләрен белергә тиеш);<br>б) аермалык турында, мәсәлән: 31-45 яшьләрдәге гражданнар белән чагыштырганда, 46-60 яшьләрдәге гражданнар кешегә граждан хокукын белү кирәк дип саный (чөнки граждан хокукы мөлкәт мөнәсәбәтләрен, милек мәсьәләләрен, шартнамәләр төзү мәсьәләләрен җайга сала, һ.б.; кагыйдә буларак, бу яшьтә күпләр төрле милеккә ия, шунлыктан биләү, файдалану һәм идарә итү мәсьәләләре аларны яшьрәк гражданнарга караганда күбрәк борчый).<br>Охшашлык һәм аермалык турында башка нәтиҗәләр булырга, башка урынлы фаразлар әйтелергә мөмкин | |
| Охшашлык һәм аермалык турында берешәр нәтиҗә формалаштырылган, аларның һәркайсы буенча урынлы фаразлар җиткерелгән | 4 |
| Бер-ике нәтиҗә формалаштырылган, берсе буенча гына урынлы фаразлар җиткерелгән | 3 |
| Ике нәтиҗә генә формалаштырылган | 2 |
| Бер генә нәтиҗә формалаштырылган | 1 |
| Биремнең таләпләренә туры килми торган гомуми характердагы фикер йөртүләр генә китерелгән.<br>ЯКИ Җавап дөрес түгел | 0 |
| *Максималь балл* | *4* |

Без белем, һөнәри күнекмәләр кеше язмышында хәлиткеч роль уйнаячак гасырга керәбез. Гел катлауланып тора торган белемнән башка эшләргә, файда китерергә мөмкин булмаячак.... Кеше яңа идеяләр кертәчәк, машина уйлый алмый торган нәрсәләр турында уйлаячак. Ә моның өчен кешенең гомуми интеллигенциясе, аның яңа әйберләр уйлый алу һәм, әлбәттә, әхлакый җаваплылык булдыру кебек, машина берничек тә үти алмый торган сәләт кирәк булачак. Кешегә авыр һәм катлаулы бурыч – кеше генә түгел, ә фән кешесе, машиналар һәм роботлар гасырындагы барлык эшләр өчен әхлакый җавап бирүче кеше булу бурычы йөкләнә. Гомуми белем киләчәк кешесен, иҗат кешесен, барлык яңалыкны уйлап табучы һәм һәрбер уйланып табылганнарга әхлакый җавап бирә торган кешене булдыра ала.

Уку, белем алу – менә нәрсә кирәк кешегә яшь чактан ук. Укырга, белем алырга һәрвакыт кирәк. Барлык күренекле галимнәр гомерләренең соңгы көненә хәтле укытып кына калмаганнар, ә үзләре дә укыганнар. Белем алудан туктасаң – укыта да алмыйсың. Чөнки белем үсә һәм катлаулана. Шуны да истә тотарга кирәк, белем алу өчен иң уңайлы вакыт – яшьлек. Нәкъ менә яшь чакта, балачакта, яшьлектә кешенең аңы күп әйберләрне кабул итәргә сәләтле.

Вакытыгызны буш нәрсәләргә, авыр эшләргә караганда да ардырта торган «ял итү»ләргә әрәм итмәгез, үзегезнең аек акылыгызны мәгънәсез «мәгълүматлар» агымы белән тутырмагыз. Үзегезне яшь чакта гына бик җиңел һәм тиз үзләштереп була торган белем һәм күнекмәләр алу өчен саклагыз.

Менә шунда мин яшь кешенең авыр итеп күрсенеп куюын ишетәм: нинди күңелсез тормыш тәкъдим итәсез сез безнең яшьләргә? Укырга гына. Ә ял, күңел ачу кайда соң? Безгә шатланырга, куанырга да ярамый мени инде?

Юк. Күнекмәләр һәм белем алу – шул ук спорт. Без анда шатлык таба алмаганда белем алу да бик авыр була. Белем алуны яратырга кирәк һәм ял һәм күңел ачу төрләренең акыллы, нәрсәгә дә булса өйрәтергә, тормышта кирәк булган нindидер сәләтләрне үстерергә ярдәм итә торганнарын сайлый белергә кирәк…

Белем алуны яратырга өйрәнегез!

*(Д.С.Лихачёв)*

**21** Текстның планын төзегез. Моның өчен текстның төп мәгънәви фрагментларын аерып чыгарыгыз һәм аларга исем кушыгыз.

| **Дөрес җавап эчтәлеге һәм бәяләү буенча күрсәтмәләр** (җавапның мәгънәсен бозмый торган башка формулировкалары рөхсәт ителә) | **Баллар** |
|---|---|
| Дөрес җавапта план пунктлары текстның төп мәгънәви фрагментларына туры килергә һәм аларның һәрберсенең төп идеясен чагылдырырга тиеш.<br>Түбәндәге мәгънәви фрагментларны ассызыкларга була:<br>1) XXI гасырда мәгарифнең роле;<br>2) фән кешесенең әхлакый җаваплылыгы;<br>3) яшьлек еллары - уку вакыты;<br>4) укуда шатлык таба белү.<br>План пунктларының фрагментның төп идеясе асылын бозмый торган һәм өстәмә мәгънә блокларын аерып чыгармый торган башка формулировкалары да китерелергә мөмкин. | |
| Текстның төп мәгънәле фрагментлары бүлеп бирелгән, аларның исемнәре (план пунктлары) һәр текстның төп идеясен чагылдыра.<br>Аерылып бирелгән фрагментларның саны төрле булырга мөмкин | 2 |
| Тексттагы мәгънәви фрагментларның яртысыннан артыгы дөрес билгеләнгән, аларның исемнәре (план пунктлары) текстның тиешле өлешләренең төп идеяләрен чагылдыра.<br>ЯКИ Текстның төп мәгънәви фрагментлары күрсәтелгән, ләкин барлык исемнәре дә (план пунктлары) текстның тиешле өлешләренең төп идеяләрен чагылдырмый. | 1 |
| Текстның төп фрагментлары бүлеп бирелмәгән.<br>ЯКИ Теге яки бу фрагментларның цитаталары булганлыктан, бүлеп бирелгән фрагментларның (план пунктлары) атамалары тиешле текст өлешләренең төп идеясенә туры килми.<br>ЯКИ Җавап дөрес түгел | 0 |
| *Максималь балл* | *2* |

**22** Автор XXI гасырда җитештерүдә кеше ролен ничек тасвирлый? Аның фикеренчә, кешегә нинди сыйфатлар кирәк булачак? (Теләсә нинди ике сыйфатны күрсәтегез.) Ни өчен, автор фикеренчә, яшь кешегә кечкенәдән үк укырга кирәк? (Текстны файдаланып, ике сәбәпне күрсәтегез.)

| **Дөрес җавап эчтәлеге һәм бәяләү буенча күрсәтмәләр**<br>(җавапның мәгънәсен бозмый торган башка формулировкалар рөхсәт ителә) | **Баллар** |
|---|---|
| Дөрес җавапта түбәндәге элементлар булырга тиеш:<br>1) беренче сорауга җавап, мәсәлән: кеше яңа идеяләр кертәчәк, машина уйлый алмаган әйберләр өстендә уйланачак;<br>2) икенче сорауга җавап, мәсәлән:<br>– кешенең гомуми интеллигентлыгы;<br>– яңаны уйлап табу сәләте;<br>– әхлакый җаваплылык;<br>*(Икенче сорауга җавап бары текстта әйтеп үтелгән ике яки берничә сыйфатны күрсәткәндә генә санала.)*<br>3) өченче сорауга җавап, мәсәлән:<br>– белемнәр һәрвакыт үсә һәм катлаулана;<br>– нәкъ яшьлектә кешенең аңы кабул итәргә сәләтле була.<br>*(Өченче сорауга җавап бары тик ике сәбәпне күрсәткәндә генә санала.)*<br>Җавап элементлары цитата формасында да, текстның тиешле фрагментларына туры килгән төп идеяләрне кыскартып бирү формасында да тәкъдим ителергә мөмкин | |
| Өч сорауга дөрес җавап бирелгән | 2 |
| Теләсә кайсы ике сорауга гына дөрес җавап бирелгән | 1 |
| Теләсә кайсы бер сорауга гына дөрес җавап бирелгән.<br>ЯКИ Биремнең таләбенә туры килми торган, гомуми характердагы фикер йөртүләр китерелгән<br>ЯКИ Җавап дөрес түгел | 0 |
| *Максималь балл* | *2* |

**23** Автор яшьләргә нинди ял һәм күңел ачу төрләре тәкъдим итә? Мондый төрләргә ике мисал китерегез; һәр очракта бу төрнең нинди сыйфат үстерүен күрсәтегез.

| **Дөрес җавап эчтәлеге һәм бәяләү буенча күрсәтмәләр**<br>(җавапның мәгънәсен бозмый торган башка формулировкалары рөхсәт ителә) | **Баллар** |
|---|---|
| Дөрес җавапта түбәндәге элементлар булырга тиеш:<br>1) <u>сораугa җавап</u>: автор безне нәрсәгәдер өйрәтергә, бездә киләчәк тормышыбыз өчен кирәк булган ниндидер сәләтләрне үстерә алган ял итү һәм күңел ачуның «акыллы» формаларын тәкъдим итә;<br>(Сорауның җавабы башка, мәгънәсе буенча якын булган формулировкада да бирелергә мөмкин).<br>2) <u>Сыйфатны күрсәткән ике мисал</u>, әйтик:<br>– спорт секциясендәге шөгыльләр көчне, җитезлекне, ихтыяр көчен, партнёрлар һәм көндәшләр белән хезмәттәшлек итә белүне үстерә;<br>– матур әдәбият әсәрләрен уку кешенең хисләрен аңларга өйрәтә, дөнья һәм кеше турындагы күзаллауларны киңәйтә.<br>(*Бәяләгәндә бары тик туры килә торган сыйфатларны күрсәткән мисаллар гына бәяләнә, ягъни сыйфатларны күрсәтмәгән мисаллар бәяләгәндә саналмыйлар*.)<br>Башка мисаллар, башка сыйфатлар китерелергә мөмкин | |
| Сорауга җавап бирелгән, ике мисал китерелгән, һәрбер очракта сыйфатлар күрсәтелгән (барлыгы биш позиция) | 3 |
| Теләсә кайсы дүрт позиция дөрес китерелгән | 2 |
| Теләсә кайсы ике-өч позиция дөрес китерелгән | 1 |
| Теләсә кайсы бер позиция дөрес китерелгән<br>ЯКИ Җавап дөрес түгел | 0 |
| *Максималь балл* | *3* |

Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәте 2022 ©

**24** Автор «һәрвакыт укырга кирәк» дип саный. Тексттан һәм җәмгыять белеменнән белгәннәрегезне файдаланып, өзлексез белем алуның кеше гомеренең буеннан-буена кирәклеген ике аргумент (аңлатма) белән раслагыз.

| **Дөрес җавап эчтәлеге һәм бәяләү буенча күрсәтмәләр** (җавапның мәгънәсен бозмый торган башка формулировкалары рөхсәт ителә) | **Баллар** |
|---|---|
| Түбәндәге аргументлар (аңлатмалар) китерелергә мөмкин:<br>1) Хәзерге дөньяда белемнәр бик тиз “искерә”, шунлыктан аларны һәрвакыт тулыландырып торырга, өстәлмәләр кертергә кирәк;<br>2) Хәзерге заман кешеләре еш эш алыштыралар, шуңа күрә даими рәвештә яңа мәгълүматны, башка төр эшчәнлекне үзләштерергә туры килә.<br>Башка аргументлар (аңлатмалар) китерелергә мөмкин. | |
| Ике аргумент (аңлатма) китерелгән. | 2 |
| Бер генә аргумент (аңлатма) китерелгән. | 1 |
| Биремннең таләбенә туры килми торган, гомуми характердагы фикер йөртүләр китерелгән<br>ЯКИ Җавап дөрес түгел | 0 |
| *Максималь балл* | *2* |

Төп гомуми белем бирү программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясен үткәрү тәртибе нигезендә (Россия Мәгариф һәм фән Министрлыгы һәм мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең 07.11.2018 ел, № 189/1513 боерыгы) Россия Юстиция министрлыгы тарафыннан 10.12.2018 ел, № 52953 теркәлде)

«64. Имтихан эшләре ике эксперт тарафыннан тикшерелә. Тикшерү нәтиҗәләре буенча экспертлар бер-берсенә бәйсез рәвештә имтихан эше биремнәренең һәр җавабы өчен баллар куялар. <...> Ике эксперт тарафыннан куелган балларда шактый аерма булган очракта, өченче тикшерү билгеләнә. Балларда сизелерлек аерма тиешле уку предметы буенча бәяләү критерийларында билгеләнгән.

Өченче эксперт элек имтихан эшен тикшермәгән экспертлар арасыннан фән комиссиясе рәисе итеп билгеләнә.

Өченче экспертка элегрәк укучының имтихан эшен тикшергән экспертлар тарафыннан куелган баллар турында мәгълүмат бирелә. Өченче эксперт куйган баллар ахыргы булып тора".

1, 5, 6, 12, 21-24 биремнәренең теләсә кайсын үтәгән өчен баллар 2 яки аннан да күбрәккә аерылып торса, бу вакытта әлеге аерма шактый сизелерлек (җитди) санала. Бу очракта өченче эксперт әлеге аерма килеп чыккан биремнәргә җавапларны гына тикшерә.

Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәте 2022 ©